ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

**22.11.2018 ел** **№ 26**

**“Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге уставы белән, җирле референдумда кабул ителгән 2018 елның 18 нче ноябрендәге 6 нчы номерлы карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында бастырып чыгарырга, Арча муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы , Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 20 нче йорт ; Татарстан Республикасы , Арча районы, Каенсар авылы, Урта урам, 25 нче йорт адреслары буенча халыкның күпләп җыелу урыннарындагы мәгълумат такталарына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңасала авыл
җирлеге башлыгы — Сафин А.И.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЯНГА-САЛСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1061683000063 * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯНГА-САЛСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» * ИНН 1609009996

Яңасала авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018
елның 22 нче
ноябрендәге
26 нчы номерлы
карарына 1 нче
кушымта

**“Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Үзара салым акчасы 18 яшькә җиткән һәм Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, җирле референдумда катнашу-катнашмауга, тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә 2019 елның 21 нче февраленә кадәр түләнә.

3. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) көндезге бүлектә укучы студентларга,

б) 1 нче группа инвалидларга,

в) 70 яшьтэн өлкән гражданнарга,

түләү күләме җирле референдум карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (эти-энисе, тормыш иптәше, балалары) үлеме,

б) янгыннан һәм бәлә-казадан зыян күрү,

өч айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгару, Арча муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы , Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 20 нче йорт ; Татарстан Республикасы , Арча районы, Каенсар авылы, Урта урам, 25 нче йорт адреслары буенча халыкның күпләп җыелу урыннарындагы мәгълүмат такталарына урнаштыру, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша халыкка җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

6. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары “Яңасала авыл

җирлеге" муниципаль берәмлеге шәхси хисабына күчерелә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыруга һәм почта аша күчерүгә хокуклы оешмалар, Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша башкарыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Билгеләнгән вакытта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

“Яңасала авыл җирлеге” униципаль берәмлеге башкарма комитетының 2018 елның 22 нче ноябрендәге 26 нчы номерлы карарына 2 нче кушымта

Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № ______

Түләүченең Ф.И.Ә.И.
______________________________________________________________
Адресы:________________________________________________________
Нигезләмә:_____________________________________________________
Сезгә ______________________ кадәрге вакыт эчендә ____________________________________ чараны гамәлгә ашыру буенча ____________ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:
Кабул итүче як банкы БИК _________________________________
Сч. № ______________________________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № ___________________________________
ИНН ____________________________________
КПП ____________________________________
КБК ______________ОКАТО _________________
Түләүнең билгеләнеше_____________________________________
Җитәкче ________________ ________________________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - - - -

“Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне _______________ сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.И.
______________________________________________________________
Адресы:________________________________________________________
Кабул ителде «__» ___________ 20__ ел. __________________________
(түләүченең имзасы/ фамилиясе)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм Яңасала авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*